Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № II-3**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 6 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 24 июлендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләре турында" гы XXXII-11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Урманга кагылышлы законнарны бозу аркасында урманнарга һәм алардагы табигый объектларга китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында" 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 24 июлендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләре турында" XXXII-11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә юк ителә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерүне үткәрү методикасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 4.5, 4.6. пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау Кагыйдәләренә кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов